МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.06.2015 № 435

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 22 июлендә теркәлде, № 2805

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә
мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр
күрсәтүнең индивидуаль программасын
төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау хакында

“Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” 28 декабрь, 2013 ел, № 442-ФЗ Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатыннан боерык бирәм:

1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. “Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәләре (бүлекләре) җитәкчеләренә, “Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика мәгълүмат-методика үзәге” дәүләт казна учреждениесе җитәкчесенә: Регламент нигезләмәләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Ю.И.Әбдриевага йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланды

**Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар булып Россия Федерациясенең социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ гражданнары, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар, качаклар тора, әгәр аларның тормышын начарайтучы яки начарайтырга мөмкин түбәндәге шартлар булса:

1) авыру, җәрәхәт, яшь яки инвалидлык булу аркасында үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, төп тормыш ихтыяҗларын тәэмин итү сәләтен яисә мөмкинлеген тулысынча яки өлешчә югалту;

2) гаиләдә даими рәвештә читләр каравына мохтаҗ булган инвалид яки инвалидлар, шул исәптән инвалид бала яки инвалид балалар булу;

3) социаль яраклашуда кыенлыклар кичерүче бала яки балалар (шул исәптән опекада, химаячелектә торган) булу;

4) инвалидны, баланы, балаларны карауны (шул исәптән вакытлыча) тәэмин итү мөмкинлеге булмау;

5) гаилә эчендә низаг булу, шул исәптән наркотикларга яки алкогольгә бәйлелектәге затлар белән, комарлы уеннарга һәвәс затлар белән, психикасы бозылудан интегүче затлар белән; гаиләдә көч кулланунның булуы;

6) билгеле бер яшәү урыны булмау, шул исәптән егерме өч яшькә җитмәгән һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен булган оешмада яшәп торуын тәмамлаган затның;

7) эш һәм яшәү өчен акча булмау;

8) гадәттән тыш хәлләр, кораллы халыкара (этносара) низаглар нәтиҗәләре.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә мөрәҗәгать итүчеләр булып дәүләт хезмәте алучылар (аларның законлы вәкилләре) яисә алар мәнфәгатендә эш итүче башка гражданнар, шулай ук дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр тора.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан, дәүләт хезмәте алучының яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы

муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәләре (бүлекләре) (алга таба – Министрлыкның территориаль органнары) йөзендә күрсәтелә.

Гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗлыгын билгеләүдә һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзүдә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына буйсынучы, әлеге функцияләр йөкләнгән "Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика мәгълүмат-методика үзәге" социаль хезмәт күрсәтү дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Учреждение) катнаша.

1.4.1. Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль органнарының, Учреждениенең урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адреслары турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) сайтында (http://www.mtsz.tatarstan.ru) "Территориаль органнар һәм буйсынучы учреждениеләр" бүлегендә, шулай ук бу Регламентка белешмә-кушымтада күрсәтелгән.

Министрлыкның территориаль органнарының эш графигы: дүшәмбе – җомга: 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькәчә; шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Учреждениенең эш графигы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе: 09.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькәчә; җомга: 09.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькәчә; шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

1.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Министрлыкның территориаль органнарында, Учреждениедә урнашкан, хезмәт күрсәтү турындагы визуаль һәм текстлы мәгълүматы булган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында бу Регламентның 1.4.1, 1.5, 2.3 – 2.5, 2.8, 2.10, 5.1 – 5.9 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат булырга тиеш;

2) "Интернет" челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында – http://www.mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://www.uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка, Министрлыкның территориаль органына, Учреждениегә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Учреждениегә, Министрлыкның территориаль органына, Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

1999 елның 24 июнендәге "Балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын булдырмау системасының нигезләре турында" № 120-ФЗ

Федераль закон (алга таба – № 120-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 26, 3177 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2013 елның 28 декабрендәге “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтүнең нигезләре турында” № 442-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 442-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52 (1 өлеш), 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2008 елның 4 августындагы “Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасының, инвалид баланы тернәкләндерүнең индивидуаль программасының федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелүче формаларын, аларны төзү һәм тормышка ашыру тәртибен раслау турында” № 379н боерыгы (алга таба – РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының № 379н боерыгы) (Российская газета, № 190, 10.09.2008, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 28 мартындагы “Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза формасын раслау турында” № 159н боерыгы (алга таба – РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының № 159н боерыгы) (Российская газета, № 131, 16.06.2014, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 10 ноябрендәге “Социаль хезмәтләр күрсәтү турында килешүнең үрнәк формасы турында, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы формасы турында” № 874н боерыгы (алга таба – РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының № 874н боерыгы) (Российская газета, № 1, 12.01.2015, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2014 елның 18 декабрендәге № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законы (алга таба – № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законы) (“Татарстан Дәүләт Советы хәбәрләре”, 2014, № 12 (II өлеш), 1361 ст.);

Гражданинны мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзүнең 25.11.2014, № 908 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган тәртибе (алга таба – ТР МК № 908 карары белән расланган Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2014, № 91-92, 2848 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтне өйдә күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең 29.12.2014, № 1053 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган тәртибе (алга таба – ТР МК № 1053 карары белән расланган Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2015, № 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтне социаль хезмәтләр күрсәтүнең стационар рәвешендә күрсәтүнең 31.12.2014, № 1100 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган тәртибе (алга таба – ТР МК № 1100 карары белән расланган Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2015, № 23-24, 0785 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтне социаль хезмәтләр күрсәтүнең ярым стационар рәвешендә күрсәтүнең 31.12.2014, № 1101 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган тәртибе (алга таба – ТР МК № 1101 карары белән расланган Тәртип);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгының территориаль органы турында типовой нигезләмә” 03.04.2006, № 144 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2006, № 14, 0365 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итүнең “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында” 07.08.2002 ел, № 674 Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2012, № 59, 2041 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү (алга таба социаль хезмәт күрсәтү) – гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлек;

социаль хезмәт – гражданинга, аның тормыш шартларын яхшырту һәм (яки) аңа үзенең төп тормыш ихтыяҗларын мөстәкыйль тәэмин итү мөмкинлекләрен киңәйтү максатларында, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә даими, вакыт-вакыт, бер тапкыр, шул исәптән вакытлыча ярдәм күрсәтү буенча гамәл яки гамәлләр;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү "тәрәзә"се;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать (27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункт). Гаризаның формасы РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының № 159н боерыгы белән расланды.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү | № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законының 7 ст. 2 өл. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы (шәһәр округларындагы) Социаль яклау идарәләре (бүлекләре) йөзендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законының 7 ст. 2 өл. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Дәүләт хезмәте күрсәтүне нәтиҗәсе булып тора:<br>гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм аңа социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын (алга таба – ИППСУ) бирү;<br>гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту | № 442-ФЗ Федераль законның 15 ст. 2 өл. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар гариза бирелгән көннән алып биш эш көне эчендә кабул ителә.<br>Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кичекмәстән кабул ителә.<br>Гражданинга социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү һәм бирү гариза бирелгән көннән алып ун эш көненнән артмаган срокта башкарыла.<br>Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы төезлми. | № 442-ФЗ Федераль законның 15 ст. 2 өл.<br>№ 442-ФЗ Федераль законның 16 ст. 4 өл.<br>№ 442-ФЗ Федераль законның 21 ст. 2 өл. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү | Билгеләнгән формадагы гариза. Гаризаның формасы РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының № 159н боерыгы белән расланды. | РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының |

| | | |
|---|---|---|
| өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе | Өендә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 1 нче кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернатларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус йорт-интернатларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Психоневрология интернатларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Акылга зәгыйфь балалар өчен балалар йортлары-интернатларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен йорт-интернатларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 4 нче кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 5 нче кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, балигъ булмаган балалар өчен социаль тернәкләндерү үзәкләрендә) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 6 нчы кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 7 нче кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт | № 159н боерыгы;<br>№ 1053 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 28 п.;<br>№ 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.1 п.;<br>№ 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 3.1 п.;<br>№ 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 4.1 п.;<br>№ 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 5.1 п.;<br>№ 120-ФЗ Федераль законның 13 ст. 3 п;<br>№ 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 6.3.3 п.;<br>№ 908 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 9 п.;<br>№ 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 7.1 п.;<br>№ 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.1 п.;<br>№ 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 3.1 п.;<br>№ 1100 ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтү комплекслы үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәтләр турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 8 нче кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәтләр турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 9 нчы кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра.<br>Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәгендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәтләр турында гариза белән бергә гариза бирүче бу Регламентның 10 нчы кушымтасы нигезендә документлар исемлеген тапшыра. | белән расланган Тәртипнең 4.1 п. |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәҗом.əн электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе; документларны үз карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Гражданинны өендә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 11 нче кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернатларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус йорт-интернатларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 12 нче кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны психоневрология интернатларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 13 нче кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны акылга зәгыйфь балалар өчен балалар йортлары-интернатларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен йорт-интернатларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 14 нче кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре | № 210-ФЗ Федераль законның 7 ст. 1 өл. 2 п;<br>РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының № 379н боерыгына 3 нче кушымтаның I өл. 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 15 нче кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, балигъ булмаган балалар өчен социаль тернәкләндерү үзәкләрендә) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 16 нчы кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 17 нче кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 18 нче кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 19 нчы кушымтада санап кителгән.<br>Гражданинны сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәгендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, документлар исемлеге бу Регламентка 20 нче кушымтада санап кителгән.<br>Югарыда күрсәтелгән документларны гариза бирүчеләр үзләре тапшырырга хокуклы.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | нигез булып тормый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерергә тиешле (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы хәл итә) дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Гариза һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып торалар:<br>1) бу Регламентның 1.3 пункты нигезендә гариза бирүче булып тормаучы затның мөрәҗәгать итүе;<br>2) гражданинны тиешле формада социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, бу Регламентның 2.5 пункты белән күздә тотылган документларны (документларның күчермәләрен) тапшырмау яки тапшырып бетермәү;<br>3) гамәлдә булу срогы чыккан документлар (документларның күчермәләре) һәм мәгълүматлар тапшыру, документларда (документлар күчермәләрендә) билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып торалар:<br>1) дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар тапшыру, гамәлдә булу срогы чыккан документлар һәм мәгълүматлар тапшыру;<br>2) гражданинның тормыш алып бару шартларын начарайта торган яки начарайтырга мөмкин булган хәлләрнең булмавы;<br>3) социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен медицина ягыннан Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары белән күздә тотылган каршылыклар ачыклану.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән. | № 908 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 13 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | № 210-ФЗ Федераль законның 8 ст. |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең максималь срогы 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы | Социаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, шул исәптән электрон рәвештә җибәрелгәнен дә теркәү гариза кергән моменттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган урыннарда башкарыла.<br>Гариза кабул итүгә җаваплы һәр белгечнең эш урыны кирәкле мәгълүмат базаларына, “Интернет” челтәренә керү мөмкинлеге булган персональ компьютер, кәгазьгә бастырып чыгару җайланмасы (принтер) һәм күчермә ясаучы җайланма белән җиһазланган булырга тиеш. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;<br>дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы;<br>гариза бирүчеләрнең Министрлыкның территориаль органы белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан-туры – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>әгәр гариза һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп электрон имза куелган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләр белән аралашуы дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп) дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны гариза бирүче http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлыкның территориаль органына, № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, гариза бирүченең электрон имзасы белән имзаланган гариза Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http:// uslugi.tatar.ru) аша җибәрелергә мөмкин. | № 63-ФЗ Федераль законның 2 ст. 11 п.;<br>№ 210-ФЗ Федераль законның 21.1 ст. |

**3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән электрон рәвештә) түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны һәм тапшырылган документларны карап тикшерү, социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү;

4) Учреждение белгеченең гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырган, һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алынган (тапшырылган) документларның (мәгълүматларның) бу Регламентның 2.9 пункты таләпләренә туры килүен карап тикшерүе: гражданинның тормыш алып ару шартларын начарайта торган яки начарайтырга мөмкин булган хәлләрнең булуын (булмавын) билгеләве;

5) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү;

6) Гражданинның социаль хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль мохтаҗлыгын билгеләү, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын (алга таба – ИППСУ) төзү һәм гражданинга бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 21 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.1. Гариза бирүче консультация алу өчен, яшәү урынында Министрлыкның территориаль органына шәхсән үзе, телефоннан, язмача почта аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итә. Консультация алу өчен документлар күчермәләре, электрон рәвештә, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелергә мөмкин.

Министрлыкның территориаль органы белгече, гариза бирүчегә

консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып торалар: тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны һәм тапшырылган документларны карап тикшерү, социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.1. Гариза бирүче үзенең яшәү урынындагы территориаль органга гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктына туры китереп документлар бирә.

Гариза һәм документларның билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон почта аша җибәрелүче гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә имзалана һәм электрон җайланмалардан файдаланып һәм (яки) Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша территориаль органга тапшырыла.

Почта аша җибәрелгән яки Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә тапшырылган гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) гомуми тәртиптә карап тикшерелә.

3.5.2. Министрлыкның территориаль органы белгече гаризаны һәм тапшырылган документларны (документлар күчермәләрен) тикшерә.

Гаризаны теркәүдән һәм документларны (документлар күчермәләрен) кабул итүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.8 пункты белән күздә тотылган нигезләр булган очракта, Министрлыкның территориаль органы белгече гариза бирүчегә гаризаны һәм документларны (документлар күчермәләрен) кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуга нигезләр булу турында җиткерә һәм, гаризаны һәм (яки) документларны (документлар күчермәләрен) кабул итүдән баш тартуның ачыкланган нигезләренең эчтәлеген аңлатып, гаризаны һәм (яки) документларны (документлар күчермәләрен) аңа кире кайтара.

Гаризаны һәм документларны (документлар күчермәләрен) кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы белгече:

гаризаны гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын бозу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында (алга таба – гаризалар теркәү журналы) терки. Гаризалар теркәү журналының формасы бу Регламентка 22 нче кушымтада китерелә;

гариза бирүчегә гаризасын һәм документларын (документлар күчермәләрен) кабул итү турында гаризаны теркәү датасы, бирелгән керү номеры турында билге белән расписка тапшыра, ә гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) почта аша яки Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелгән очракта, гариза бирүчегә гаризасы һәм документлары (документлар күчермәләре) кабул ителү турында хәбәрнамә җибәрә;

Гаризаны һәм тапшырылган документларны Учреждениегә тапшыра.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза бирүчедән гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып торалар: гариза һәм документларны (документлар күчермәләрен) теркәмичә, баш тартуның нигезләрен күрсәтеп, кире кайтару; гаризалар теркәү журналында теркәү язуы булдыру, гаризаны теркәү датасы, бирелгән керү номеры турындагы билге белән бирелгән расписка яки гариза һәм документларның (документлар күчермәләренең) кабул ителүе турында хәбәрнамә; Учреждениегә тапшырылган гариза һәм документлар (документлар күчермәләре).

3.4. Дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү.

3.4.1. Тапшырылган документлар составында бу Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, гариза бирүче үзе тапшыруга хокуклы булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар булмаган очракта, Учреждение белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, соралучы мәгълүматлар алар карамагында булган дәүләт органына, җирле үзидарә органына, дәүләт органына яки җирле үзидарә органына буйсынучы оешмага тиешле рәсми мөрәҗәгать (рәсми мөрәҗәгатьләр) җибәрә.

Бу пунктча билгели торган процедура гариза теркәлгән көнне үтәлә.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, мәгълүматлар бирү хакында рәсми мөрәҗәгатьләр тора.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгече Учреждениегә соралучы мәгълүматлар алар карамагында булган дәүләт органына, җирле үзидарә органына, дәүләт органына яки җирле үзидарә органына буйсынучы оешмага рәсми мөрәҗәгать кергән моменттан башлап ике көн эчендә бирә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып тапшырылган мәгълүматлар тора. 3.5. Учреждение белгеченең гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырган, һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алынган (тапшырылган) документларның (мәгълүматларның) бу Регламентның 2.9 пункты таләпләренә туры килүен карап тикшерүе: гражданинның тормыш алып ару шартларын начарайта торган яки начарайтырга мөмкин булган хәлләрнең булуын (булмавын) билгеләве

3.5.1. Учреждение белгече гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырган, һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алынган (тапшырылган) документларның (мәгълүматларның) бу Регламентның

2.9 пункты таләпләренә туры килүен карап тикшерә:

Гаризада күрсәтелгән мәгълүматларны “Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – мәгълүмат системасы) “Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру” подсистемасына кертә;

Дәүләт хезмәте алучының тормыш алып бару шартларын начарайта торган яки начарайтырга мөмкин булган хәлләрнең булу-булмавын раслау өчен кирәкле, шулай ук социаль хезмәтләр алуга медицина ягыннан каршылыклар булу (булмау) турында таныклаучы документларны (документлар күчермәләрен) (мәгълүматларны) өйрәнә, тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген тикшерә.

3.5.2. Гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырган, һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алынган (тапшырылган) документлар (мәгълүматлар) бу Регламентның 2.9 пункты таләпләренә туры килмәгән очракта, Учреждение белгече:

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын әзерли (карарның формасы 23 нче кушымтада китерелә);

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында мәгълүмат системасында әзерләнгән карар проектын кәгазьдә бастырып чыгара;

кабул ителгән карар турында гариза бирүче адресына хәбәрнамә проектын әзерли;

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын һәм гариза бирүче адресына хәбәрнамә проектын Министрлыкның территориаль органына җибәрә.

3.5.3. Гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырган, һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алынган (тапшырылган) документлар (мәгълүматлар) бу Регламентның 2.9 пункты таләпләренә туры килгән очракта, Учреждение белгече:

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар проектын әзерли (карарның формасы 23 нче кушымтада китерелә);

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында мәгълүмат системасында әзерләнгән карар проектын кәгазьдә бастырып чыгара;

кабул ителгән карар турында, ИППСУны төзүнең көне һәм урыны турында гариза бирүче адресына хәбәрнамә проектын әзерли;

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында әзерләнгән карар проектын һәм гариза бирүче адресына хәбәрнамә проектын Министрлыкның территориаль органына җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар, гариза Министрлыкның территориаль органында теркәлгән көннән башлап дүрт эш көне эчендә, ә ашыгыч хезмәтләр күрсәтү турында гариза карап тикшерелгән очракта кичекмәстән үтәлә.

Административ процедуралар нәтиҗәсе булып, Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар проекты һәм гариза бирүче адресына хәбәрнамә проекты тора.

3.6. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү.

3.6.1. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар (алга таба – карар) кабул итә һәм шул хактагы карар проектын һәм гариза бирүче адресына хәбәрнамә проектын имзалый.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура бу Регламентның 3.5 пункты белән күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан башлап бер эш көне эчендә, ә ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар ителгән очракта кичекмәстән үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе тарафыннан имзаланган карар һәм гариза бирүче адресына хәбәрнамә тора.

3.6.2. Министрлыкның территориаль органы белгече имзаланган карарны һәм гариза бирүче адресына хәбәрнамәне алар Министрлыкның территориаль җитәкчесе тарафыннан имзаланган көнне Учреждениегә тапшыра.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура карар проекты һәм хәбәрнамә проекты Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе тарафыннан имзаланган көнне үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, Учреждениегә тапшырылган карар һәм гариза бирүче адресына хәбәрнамә тора.

3.6.3. Учреждение белгече гариза бирүче адресына хәбәрнамәне кәгазьдә яки электрон рәвештә җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура карар проекты һәм хәбәрнамә проекты Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе тарафыннан имзаланган көнне үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, гариза бирүче адресына җибәрелгән хәбәрнамә тора.

3.7. Гражданинның социаль хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль мохтаҗлыгын билгеләү, ИППСУны төзү һәм гражданинга бирү

3.7.1. Гариза бирүче тапшырган яки ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алынган, шул исәптән гаиләнең составын һәм гражданинның тормыш алып бару шартларын (гаилә әгъзаларының мохтаҗ гаилә әгъзаларын карау йөкләмәләре һәм (яки) мөмкинлекләре булу яки булмау, балигъ булмаган балалар булу, гаиләдә гаилә эчендәге низаглар булу, гаиләнең яки ялгыз гражданинның керемнәре дәрәҗәсе һәм башка шартлар) сыйфатлаучы документлар (документлар күчермәләре) һәм мәгълүматлар нигезендә, Учреждение белгече дәүләт хезмәте алучының социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль мохтаҗлыгын билгели.

Социаль хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль мохтаҗлыкны билгеләү нәтиҗәләре буенча Учреждение белгече мәгълүмат системасында РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының № 159н боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә ИППСУ проектын әзерли. Гражданин (законлы вәкиле) ИППСУны төзегәндә катнашырга хокуклы. ИППСУны социаль куркыныч халәттә булган, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган балигъ булмаган балага төзегәндә, ИППСУ балигъ булмаган баланы тернәкләндерүнең муниципаль, социаль тернәкләндерү консилиумы тарафыннан төзелүче һәм расланучы индивидуаль программасын исәпкә алып төзелә.

ИППСУ проекты төзелгәннән соң Учреждение белгече аның кәгазьдәге ике нөсхәсен Министрлыкның территориаль органына карап тикшерү һәм имзалау өчен җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура бу Регламентның 3.6.2 пунктчасы белән күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан башлап өч эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, ИППСУның Министрлыкның территориаль органына карап тикшерүгә һәм имзалауга җибәрелгән ике нөсхәдәге проекты тора.

3.7.2. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе ИППСУны карап тикшерә һәм имзалый һәм Учреждениегә аны гариза бирүчегә тапшыруны оештыру өчен җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура бу Регламентның 3.7.1 пунктчасы белән күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, ИППСУның Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм Учреждениегә җибәрелгән ике нөсхәдәге проекты тора.

3.7.3. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе тарафыннан имзаланган ике нөсхәдәге ИППСУ алынганнан соң Учреждение белгече дәүләт хезмәте алучының яки аның законлы вәкилен ИППСУ белән таныштыра (анда дәүләт хезмәте алучы яки аның законлы вәкиле үзләренең имзаларын куя), дәүләт хезмәте алучыга яки аның законлы вәкиленә ИППСУның бер нөсхәсен бирә һәм бер нөсхәсен Министрлыкның территориаль органына җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура бу Регламентның 3.7.2 пунктчасы белән күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, имзаланган һәм бер нөсхәсе дәүләт хезмәте алучыга яки аның законлы вәкиленә бирелгән ИППСУ һәм бер нөсхәсе Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән ИППСУ тора.

3.8. Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.

3.9. Техник хаталарны төзәтү.

3.9.1. ИППСУда техник хата табылган очракта, дәүләт хезмәте алучы яки аның законлы вәкиле Министрлыкның территориаль органына тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында 25 нче кушымта нигезендә гариза;

дәүләт хезмәте алучыга яки аның законлы вәкиленә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы ИППСУны;

техник хата булуын таныклаучы документлар (документлар күчермәләре).

ИППСУда күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гаризаны дәүләт хезмәте алучы яки аның законлы вәкиле шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып), яисә Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша бирә.

3.9.2. Министрлыкның территориаль органының документларны кабул итүгә җаваплы белгече гаризаны һәм документларны (документлар күчермәләрен) карап тикшерә.

ИППСУда техник хата булган очракта, Министрлыкның территориаль органы белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны техник хатаны төзәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында (26 нчы кушымта) терки;

гаризаны теркәү көне турында билге белән һәм ИППСУ бирелү көнен һәм урынын күрсәтеп, гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) кабул ителү турында дәүләт хезмәте алучыга яки аның законлы вәкиленә расписка тапшыра;

гариза һәм документларны (документлар күчермәләрен) Учреждениегә тапшыра.

ИППСУда техник хата булмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы белгече дәүләт хезмәте алучыга яки аның законлы вәкиленә ИППСУда техник хата булмау турында хәбәр итә һәм, гариза һәм (яки) документларны (документлар күчермәләрен) кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуның сәбәпләрен аңлатып, аңа гаризасын һәм (яки) документларын (документлар күчермәләрен) кире кайтара.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедуралар техник хатаны төзәтү турында гариза кергән көнне үтәлә.

Административ процедуралар нәтиҗәсе булып, гаризаны һәм документларны (документлар күчермәләрен) теркәмичә кире кайтару яисә техник хатаны төзәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында гаризаны теркәү хакында теркәү язуы; гаризаны теркәү көне турында билге белән һәм ИППСУ бирелү көнен һәм урынын күрсәтеп, гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) кабул ителү турында гариза бирүчегә тапшырылган расписка; Учреждениегә тапшырылган гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) тора.

3.9.3. Учреждение белгече:

мәгълүмат системасында ИППСУга төзәтмәләр кертә;

ИППСУны ике нөсхәдә кәгазьдә бастырып чыгара;

дәүләт хезмәте алучы адресына техник хатаның төзәтелүе турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) проектын әзерли;

ИППСУның ике нөсхәсен һәм хәбәрнамә проектын Министрлыкның территориаль органына имзалауга җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедуралар техник хатаны төзәтү

турында гариза кабул ителгән көнне үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән ике нөсхәдә ИППСУ проекты һәм хәбәрнамә проекты тора.

3.9.4. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе ике нөсхәдә ИППСУны, хәбәрнамәне имзалый һәм Учреждение белгеченә җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура бу Регламентның 3.9.3 пунктчасы белән күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, имзаланган һәм Учреждениегә җибәрелгән ике нөсхәдә ИППСУ һәм хәбәрнамә тора.

3.9.5. Учреждение белгече бу Регламентның 3.7.3 пунктчасы белән күздә тотылган процедураларны башкара.

Дәүләт хезмәте алучы яки аның законлы вәкиле распискада күрсәтелгән вакытта килмәгән очракта, Учреждение белгече аңа хәбәрнамә җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура бу Регламентның 3.9.3 пунктчасы белән күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, дәүләт хезмәте алучыга яки аның законлы вәкиленә бирелгән ИППСУ, ә дәүләт хезмәте алучы яки аның законлы вәкиле распискада күрсәтелгән вакытта килмәгән очракта, аңа җибәрелгән хәбәрнамә тора.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгатькә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып:

- делопроизводствоны алып баруга, шул исәптән гаризалар һәм документларны (документлар күчермәләрен) кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүгә;

- гаризалар һәм документларны (документлар күчермәләрен) карап тикшерү нәтиҗәләренең законнар (бу Регламент) таләпләренә туры килүенә;

- дәүләт хезмәте күрсәтүнең сроклары, тәртибе үтәлүгә тикшерүләр үткәрү тора.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлек

Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе һәм Учреждение җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итүне министрның шуның белән шөгыльләнүче урынбасары башкара.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контрольлек итү Министрлыкның территориаль органы эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

4.5. Дәүләт хезмәте алганда, гражданнарның хокуклары бозылу уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законына туры китереп җаваплылыкка тартыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр тәртиптә министрның шуның белән шөгыльләнүче урынбасарына (министрга) шикаять белдерүгә хокуклы.

Министрның шуның белән шөгыльләнүче урынбасарының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр министрга бирелә. Министрның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны (документлар күчермәләрен) гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан

Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлыкның территориаль органы, Министрлыкның территориаль органының вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән ИППСУда җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә. Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль органының, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль органы вазыйфаи затының гариза бирүчедән гаризасын кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерү очрагында – аны теркәүгә алганнан соң биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүче – карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелә торган – территориаль органының, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль органы вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең атамасы;

2) гражданинның – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүченең – юридик затның – атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятькә шикаятьне тапшырган дәүләт хезмәте алучы имза сала.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бу Регламентның 5.1

пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерәләр, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль орган тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарталар.

Бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гражданинга язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча, электрон рәвештә, шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 1 нче кушымта

**Гражданинны социаль хезмәтне өендә күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче үзенең яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның бирелгән көненнән башлап гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Социаль хезмәтләр алучының шәхесен таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәте идарәсенең Татарстан Республикасындагы территориаль органы | Законга туры китереп |
| 2. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә | “Медицина-социаль экспертизаның Татарстан Республикасындагы баш бюросы” федераль казна учреждениесенең структур бүлекчәләре | Белешмәдә күрсәтелгән |
| 3. | Инвадидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр | “Медицина-социаль экспертизаның Татарстан Республикасындагы баш бюросы” федераль казна учреждениесенең | Инвалидны тернәкләндерүнең Медицина-социаль экспертизаның Татарстан Республикасындагы баш бюросының |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | төзелгән һәм бирелгән, яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән инвалидлар өчен) | структур бүлекчәләре | территориаль бүлекчәсе тарафыннан бирелгән индивидуаль програмамсында күрсәтелгән көнгә кадәр |
| 4. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен медицина ягыннан каршылыклар булу (булмау) турында медицина оешмасының йомгаклау нәтиҗәсе | Дәүләт медицина оешмасы | Законга туры китереп |
| 5. | Гражданинның, аның гаиләсе әгъзаларының акчалата алынган, “Социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтү өчен җан башына уртача keremне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 18.10.2014 ел, № 1075 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына һәм социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган керемнәре булу (булмау) турындагы документлар (мәгълүматлар) | Керемнәр булу (булмау) турындагы документларны (мәгълүматларны) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | Законга туры китереп |
| 6. | Социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтергә хокукны раслаучы, билгеләнгән үрнәктәге документ | Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар | Билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелгән |

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 2 нче кушымта

**Гражданинны картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернатларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус йорт-интернатларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче үзенең яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның бирелгән көненнән башлап гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәте идарәсенең Татарстан Республикасындагы территориаль органы | Законга туры китереп |
| 2. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Белешмәдә күрсәтелгән |
| 3. | Инвадидны тернәкләндерүнең Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән, яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән индивидуаль | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | программасы | | |
| 4. | Амбулатор сырхауның медицина картасыннан эчәк инфекцияләрен китереп чыгаручылар төркеменә; дифтериягә бактериология тикшеренүләре; бабасыр йомыркаларына; венерик авыруларга (сифилис, гонорея); ВИЧ-инфекциягә; туберкулезга тикшерүләр турындагы мәгълүматларны үз эченә алучы өземтә | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |
| 5. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен медицина ягыннан каршылыклар булмау турында медицина оешмасының йомгаклау нәтиҗәсе | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |
| 6. | Яшәү урынында йогышлы авырулар булмау турында белешмә | Медицина оешмалары | 3 көн |
| 7. | Административ күзәтчелек билгеләү турында суд карары күчермәсе <*> | Суд органнары | Законга туры китереп |
| 8. | Төзәтү урчеждениесеннән азат ителү турындагы, административ күзәтчелек билгеләнү хакында билге куелган белешмәнең күчермәсе <*> | Төзәтү учреждениесе | Законга туры китереп |
| 9. | Төзәтү учреждениесе администрациясе тарафыннан бирелгән, килеп җитү срогы күрсәтелгән, сайлап алынган яшәү яки булу урынына чыгып китү турында күрсәтмәнең күчермәсе <*> | Төзәтү учреждениесе | Законга туры китереп |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Гражданинны административ күзәтчелекнең башкару өчен исәпкә кую турында мәгълүматлар <*> | Эчке эшләр органнары | Законга туры китереп |
| 11. | Гражданинның ташламалы категориягә кертүне раслаучы, билгеләнгән үрнәктәге документ <**> | Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар һәм комиссияләр | Билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелгән |
| 12. | Гражданинның, аның гаиләсе әгъзаларының акчалата алынган, “Социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтү өчен җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 18.10.2014 ел, № 1075 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына һәм социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган, соңгы 12 айда алынган керемнәре булу (булмау) турындагы документлар (мәгълүматлар) <***> | Керемнәр булу (булмау) турындагы документларны (мәгълүматларны) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | Законга туры китереп |

--------------------------------

<*> - картлар һәм инвалидлар өчен махсус йорт-интернатларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү өчен гариза биргәндә тапшырыла;

<**> - № 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.2.2 пунктында күрсәтелгән ташламалы категорияләр гражданнары өчен тапшырыла;

<***> - № 1100 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.2.2 пунктында күрсәтелгән ташламалы категорияләр гражданнары өчен тапшырылмый.

Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты гариза бирүченең

шәхси документлары күчермәләрен төп нөсхәләрне күрсәтү факты буенча үзе раслый.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 3 нче кушымта

**Гражданинны психоневрология интернатларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Бирелгән көненнән башлап, документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы | Законга туры китереп |
| 2. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Белешмәдә күрсәтелгән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | ТИП Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән инвалид өчен Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән |
| 4. | Амбулатор сырхауның медицина картасыннан эчәк инфекцияләре, дифтерия китереп чыгаручылар төркеменә бактериологик тикшерүләр; бабасыр йомыркаларына; венерик авыруларга (сифилис, гонорея); ВИЧ-инфекциягә; туберкулезга тикшерүләр турындагы мәгълүматларны үз эченә алган өземтә | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |
| 5. | Стационар формада социаль хезмәтләр алу өчен медицина ягыннан каршылыклар булмау турында йомгаклау нәтиҗәсе | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |
| 6. | Яшәү урынында йогышлы чирләр булмау турында | Медицина оешмалары | 3 көн |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | белешмә | | |
| 7. | Гражданинны психоневрология интернатына җибәрү турында опека һәм химаячелек органы карары (социаль хезмәт алучыларның закон белән билгеләнгән тәртиптә акылга җиңел дип танылган, үзләренең халәтләре буенча шәхси гариза бирергә сәләтсезләре өчен) | Опека һәм химаячелек органы | Законга туры китереп |
| 8. | Табиб-психиатр катнашындагы табиблар комиссиясенең социаль хезмәтләр алучының аны социаль хезмәт күрсәтүнең бүтән төрле учреждениесендә тору мөмкинлегеннән мәхрүм итәрлек психик тайпылышлары булу (социаль хезмәт алучының закон белән билгеләнгән тәртиптә акылга җиңел дип танылганы өчен) турындагы; аны акылга җиңел дип тану турындагы мәсьәләне суд каршына кую өчен нигезләр булмау хакындагы (социаль | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хезмәт алучының тулы акыллысы өчен) мәгълүматларны үз эченә алучы йомгаклау нәтиҗәсе | | |
| 9. | Социаль хезмәтләр алучыны акылга җиңел дип тану турында суд карары <*> | Суд органнары | Суд органы карарында күрсәтелгән |
| 10. | Элегрәк билгеләнгән опекунны үз вазыйфаларын үтәүдән азат итү турында опека һәм химаячелек органы акты <**> | Опека һәм химаячелек органы | Законга туры китереп |
| 11. | Гражданинны ташламалы категориягә кертүне раслаучы, билгеләнгән үрнәктәге документ <***> | Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар һәм комиссияләр | Билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелгән |
| 12. | Гражданинның яшәү урынында аның белән бергә теркәлгән затлар турында мәгълүматлар кергән документ <****> | Торакны эксплуатацияләү органнары яки җирле үзидарә органнары | 30 көн |
| 13. | Гражданинның, аның гаиләсе әгъзаларының акчалата алынган, аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә, Россия Федерация Хөкүмәтенең 2014 елның “Түләүсез | Керемнәр булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | Законга туры китереп |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | социаль хезмәтләр күрсәтү өчен, җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 18 октябрендәге № 1075 карары нигезендә исәпкә алына һәм соңгы 12 ай эчендә алынган социаль хезмәтләр күрсәткәнгә түләү күләмен исәпләү өчен файдаланыла торган керемнәре булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) <*****> | | |

--------------------------------

<*> - акылга җиңел гражданнар өчен тапшырыла;

<**> - билгеләнгән опекуны булган акылга җиңел гражданнар өчен тапшырыла;

<***> - № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 3.2.2 пунктында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырыла;

<****> - № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 3.2.2 пунктындагы “а” пунктчасында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырылмый;

<*****> - № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 3.2.3 пунктында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырылмый.

Гариза бирүченең законлы вәкиле тапшыра торган документлар исемлеге:

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Бирелгән көненнән башлап, документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы | Законга туры китереп |
| 2. | Социаль хезмәтләр алучының законлы вәкиленең статусын һәм вәкаләтен раслаучы документлар: | | |
| 2.1. | опека һәм химаячелек органы карары яисә законлы көченә кергән суд карары | Опека һәм химаячелек органы, суд органнары | Опека һәм химаячелек органы карарында күрсәтелгән;<br>суд карарында күрсәтелгән |
| 2.2. | Опекун яки химаяче вазыйфаларын башкаручы оешма җитәкчесе тарафыннан бирелгән ышанычнамә <*> | Опекун яки химаяче вазыйфаларын башкаручы оешма | Ышанычнамәдә күрсәтелгән |

--------------------------------

<*> - юридик затлар исәбендәге законлы вәкил исеменнән эш йөртүче вазыйфаи зат өчен тапшырыла.

Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты, төп нөсхәләрен күрсәтү факты буенча, шәхси документларның күчермәләрен үзе раслый.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 4 нче кушымта

**Гражданинны акылга зәгыйфь балалар өчен балалар йортлары-интернатларында, физик кимчелекләре булган балалар өчен йорт-интернатларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Бирелгән көненнән башлап, документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы | Законга туры китереп |
| 2. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Белешмәдә күрсәтелгән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Инвалидны тернәкләндерүнең Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән индивидуаль программасы | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән |
| 4. | Амбулатор сырхауның медицина картасыннан эчәк инфекцияләре, дифтерия китереп чыгаручылар төркеменә бактериологик тикшерүләр; бабасыр йомыркаларына; венерик авыруларга (сифилис, гонорея); ВИЧ-инфекциягә; туберкулезга тикшерүләр турындагы мәгълүматларны үз эченә алган өземтә | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |
| 5. | Стационар формада социаль хезмәтләр алу өчен медицина ягыннан каршылыклар булмау турында йомгаклау нәтиҗәсе | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |
| 6. | Яшәү урынында йогышлы чирләр | Медицина оешмалары | 3 көн |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | булмау турында белешмә | | |
| 7. | 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балалар өчен психология-медицина-педагогика комиссиясенең (консультациясенең) йомгаклау нәтиҗәсе | Республика яки муниципалитет психология-медицина-педагогика комиссиясе (консультациясе) | 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге яшьтә булу |
| 8. | Балигъ булмаган баланы акылга зәгыйфь балалар өчен балалар йорты-интернатына, физик кимчелекләре булган балалар өчен йорт-интернатка җибәрү турында опека һәм химаячелек органы акты <*> | Опека һәм химаячелек органы | Социаль хезмәтләр күрсәтелә башлаганга кадәр |

--------------------------------

<*> - ятим балалар өчен һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга өчен тапшырыла.

Гариза бирүченең законлы вәкиле тапшыра торган документлар исемлеге:

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Бирелгән көненнән башлап, документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы | Законга туры китереп |
| 2. | Социаль хезмәтләр алучының законлы вәкиленең статусын һәм вәкаләтен раслаучы документлар: | | |
| 2.1. | опека һәм химаячелек органы карары яисә законлы көченә кергән суд карары | Опека һәм химаячелек органы, суд органнары | Опека һәм химаячелек органы яисә суд карарында күрсәтелгән |
| 2.2. | Опекун яки химаяче вазыйфаларын башкаручы оешма җитәкчесе тарафыннан бирелгән ышанычнамә <*> | Опекун яки химаяче вазыйфаларын башкаручы оешма | Ышанычнамәдә күрсәтелгән |

--------------------------------

<*> - юридик затлар исәбендәге законлы вәкил исеменнән эш йөртүче вазыйфаи зат өчен тапшырыла.

Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты, төп нөсхәләрен күрсәтү факты буенча, шәхси документларның күчермәләрен үзе раслый.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 5 нче кушымта

**Гражданинны инвалидны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Социаль хезмәтләр алучының шәхесен таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы | Законга туры китереп |
| 2. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар <*> | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы, опека һәм химаячелек органы | Законга туры китереп |
| 3. | Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең Татарстан | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән индивидуаль программасы <**> | | күрсәтелгән |
| 4. | Сәламәтлек торышы турында төп һәм иярчен диагнозны, медицина тикшеренүе нәтиҗәләрен, стационар формада социаль хезмәтләр алу өчен медицина ягыннан каршылыклар булмау, медицина тернәкләндерүе чараларын уздыруга рөхсәтләр булу турында йомгаклау нәтиҗәсен үз эченә алган мәгълүматлар <***> | Медицина оешмалары | Сәламәтлек торышы турындагы белешмәдә күрсәтелгән |
| 5. | Яшәү урынында йогышлы чирләр булмау турында белешмә | Медицина оешмалары | 3 көн |
| Гражданинны социаль тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, өстәмә рәвештә тапшырыла: | | | |
| 6. | Гражданинны ташламалы категориягә кертүне раслаучы, билгеләнгән үрнәктәге документ <****> | Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар һәм комиссияләр | Билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелгән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Гражданинның, аның гаиләсе әгъзаларының акчалата алынган, аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә, Россия Федерация Хөкүмәтенең 2014 елның “Түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтү өчен, җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 18 октябрендәге № 1075 карары нигезендә исәпкә алына һәм соңгы 12 ай эчендә алынган социаль хезмәтләр күрсәткәнгә түләү күләмен исәпләү өчен файдаланыла торган керемнәре булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) <*****> | Керемнәр булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | Законга туры китереп |

--------------------------------

<*> - документлар балигъ булмаганнарны мохтаҗ дип таныган вакытта тапшырыла;

<**> - инвалидлар (инвалид балалар) өчен тапшырыла;

<***> - балигъ гражданнарны мохтаҗ дип таныган вакытта тапшырыла;

<****> - № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 5.2.3 пунктындагы “а” – “д” пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырыла.

<*****> - № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 5.2.3 пунктындагы “а” – “е” пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырылмый.

Гражданинны инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, I төркем инвалидларны, 7 яшькә кадәрге яшьтәге инвалид балаларны, күренүнең өченче дәрәҗәсендәге теләсә кайсы категориядә тормыш алып барулары чикләнгән инвалид балаларны озатып йөрүчеләр (алга таба – озатып йөрүчеләр) өчен тапшырылырга тиешле документлар:

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документлар | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы | Законга туры китереп |
| 2. | Яшәү урынында йогышлы чирле авырулар белән контактлар булмау турында белешмә | Медицина оешмалары | 3 көн |
| 3. | Инвалид баланың законлы вәкиленең хокукларын таныклаучы документ (паспорт яисә балага опека, химая билгеләү, баланы сыендыручы гаиләгә тапшыру турында карар) <*> | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы, опека һәм химаячелек органы | Законга туры китереп |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Инвалид баланың мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә һәм аларны яклауга билгеләнгән тәртиптә расланган ышанычнамә <**> | Нотариаль контора яки Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 185.1 статьясында һәм Россия Федерациясе Гражданнар процессуаль кодексының 53 статьясында күрсәтелгән оешма һәм учреждениеләр | Ышанычнамәдә күрсәтелгән |

--------------------------------

<*> - инвалид баланың законлы вәкиле булып торучы озатып йөрүчесе өчен тапшырыла;

<**> - инвалид баланың законлы вәкиле исеменнән эш итүче озатып йөрүчесе өчен тапшырыла.

Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты, төп нөсхәләрен күрсәтү факты буенча, шәхси документларның күчермәләрен үзе раслый.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 6 нчы кушымта

**Гражданинны социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, балигъ булмаганнар өчен социаль тернәкләндерү үзәкләрендә) социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Балигъ булмаган баланың күзәтүчесез булуын һәм хокук бозуын булдырмау системасы яки органы вазыйфаи затының үтенече (ходатайство) | Опека һәм химаячелек органы, эчке эшләр органы, сәламәтлек саклау идәрәсе органы, мәгариф идарәсе органы, яшьләр эшләре органы | Дәүләт хезмәтен алганга кадәр |
| 2. | Балигъ булмаган баланың атасының (анасының) (законлы вәкилнең) язмача гаризасы | - | Дәүләт хезмәтен алганга кадәр |
| 3. | Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) паспорты | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль | Законга туры китереп |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | органы | |
| 4. | Гражданинның Россия Федерациясе территориясендә яшәүгә хокукын раслаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең территориаль органнары | Законга туры китереп |
| 5. | Балигъ булмаган баланың паспорты (14 яшьтән өлкәнрәк балалар өчен) | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы | Законга туры китереп |
| 6. | Баланың туу турындагы таныклыгы (14 яшьтән кечерәк яисә паспорты булмаган балалар өчен) | Гражданлык хәле актларын теркәү органы | 14 яшькә җиткәнгә кадәр |
| 7. | Сәламәтлекнең торышы турында белешмә, стационар формада социаль хезмәтләр алу өчен медицина ягыннан каршылыклар булмау турында йомгаклау нәтиҗәсе | Сәламәтлек саклау учреждениесе | 30 көн |
| 8. | Балигъ булмаган баланың медицина иминиятләштерүе полисы | Иминиятләштерү медицина оешмасы | Законга туры китереп |
| 9. | Гаилә составы турында белешмә (теркәлү булганда) | Торак фондын идарә итүче оешма | 30 көн |
| 10. | Сәламәтлек саклау учреждениесенең атаны (ананы) яки законлы вәкилне (ул бердәнбер) хастаханәгә салу зарурлыгы турында белешмәсе | Сәламәтлек саклау учреждениесе | Белешмәдә билгеләнгән көнгә кадәр |
| 11. | Балигъ булмаган баланың шәхси гаризасы (язмача яки телдән) | - | Дәүләт хезмәтен алганга кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү системасына кермәүче дәүләт оешмалары, учреждениеләре, эчке эшләр органнары, җирле үзидарә органнары, балигъ булмаганнар эшләре комиссияләре, иҗтимагый берләшмәләрнең опекага, химаягә мохтаҗ баланы, инвалидны ачыклау турында мәгълүматлары; карау (шул исәптән вакытлыча) белән тәэмин итү мөмкинлеге булмау фактын раслаучы документлар (мәгълүматлар) | Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү системасына кермәүче дәүләт оешмалары, учреждениеләре, эчке эшләр органнары, җирле үзидарә органнары, балигъ булмаганнар эшләре комиссияләре, иҗтимагый берләшмәләр | Дәүләт хезмәтен алганга кадәр |
| 13. | Опека һәм химаячелек органнарының бала, инвалид турында опека яки химая билгеләүгә мохтаҗлыкларын раслаучы мәгълүматлары | Опека һәм химаячелек органнары | Дәүләт хезмәтен алганга кадәр |
| 14. | Балигъ булмаган баланы социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган учреждениегә кабул итү зарурлыгы турында район, шәһәр эчке эшләр бүлегенең (идарәсенең), башка муниципаль берәмлекнең эчке эшләр бүлегенең (идарәсенең), ябык административ-территориаль | Эчке эшләр бүлеге (идарәсе); транспортта эчке эшләр бүлеге (идарәсе) | 1 көн |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | берәмлекнең эчке эшләр бүлегенең (идарәсенең), транспортта эчке эшләр бүлегенең (идарәсенең) оператив кизү торучысы акты | | |
| 15. | Балигъ булмаган баланың ата-анасын яки законлы бүтән вәкилләрен тоткарлау, административ кулган алу, сак астына алу, кулга алуга хөкем итү, ирекләрен чикләү, ирекләреннән мәхрүм итү очракларында, дознание үткәрүче затның, тикшерүченең яки судьяның карары | Дознание, тикшерү үткәрүче орган; прокуратура; суд | Карар, суд карары белән билгеләнгән көнгә кадәр |
| 16. | Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаган баланы тернәкләндерүнең ведомствоара социаль тернәкләндерү консилиумы төзегән һәм раслаган индивидуаль программасы | Министрлыкның территориаль органы | Балигъ булмаган баланы тернәкләндерүнең индивидуаль программасында билгеләнгән көнгә кадәр |

Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты, төп нөсхәләрен күрсәтү факты буенча, шәхси документларның күчермәләрен үзе раслый.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 7 нче кушымта

**Гражданинны билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ (булганда): | | |
| 1.1. | паспорт | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы | Законга туры китереп |
| 1.2. | азат ителү турында белешмә | Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе | Документ бирелгән моменттан сроксыз |
| 2. | Пенсия таныклыгы | Россия Федерациясе Пенсия фондының яшәү (теркәлү) урынындагы территориаль органы | Документ бирелгән моменттан сроксыз |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Инвалидлык турында белешмә | “Медицина-социаль экспертизаның Татарстан Республикасындагы баш бюросы” федераль казна учреждениесенең структур бүлекчәләре | “Медицина-социаль экспертизаның Татарстан Республикасындагы баш бюросы” федераль казна учреждениесенең структур бүлекчәсе тарафыннан бирелгән белешмәдә билгеләнгән көнгә кадәр |
| 4. | Флюорография тикшерүе нәтиҗәләре белән, туберкулез булмау турында йомгаклау нәтиҗәсе | Дәүләтнеке яки муниципаль сәламәтлек саклау учреждениесе | 30 көн |
| 5. | Социаль хезмәтләрне стационар формада алу өчен медицина ягыннан каршылыклар булмау турында йомгаклау нәтиҗәсе | медицина оешмалары | Законга туры китереп |
| 6. | Гражданинны ташламалы категориягә кертүне раслаучы билгеләнгән үрнәктәге документ <*> | Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар һәм комиссияләр | Билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелгән |
| 7. | Гражданинның, аның гаиләсе әгъзаларының акчалата алынган, аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә, Россия Федерация Хөкүмәтенең 2014 елның “Түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтү өчен, җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 18 | Керемнәр булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | Законга туры китереп |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | октябрендәге № 1075 карары нигезендә исәпкә алына һәм соңгы 12 ай эчендә алынган социаль хезмәтләр күрсәткәнгә түләү күләмен исәпләү өчен файдаланыла торган керемнәре булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) <**> | | |

--------------------------------

<*> - № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 7.2.2 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырыла;

<**> - № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 7.2.2 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырыла.

Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты, төп нөсхәләрен күрсәтү факты буенча, шәхси документларның күчермәләрен үзе раслый.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 8 нче кушымта

**Гражданинны гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең территориаль органы, хәрби комиссариат бүлеге, Россия Федерациясе Чит илләр белән эшләү министрлыгының Консуллык департаменты, гражданлык хәле актларын теркәү территориаль органы, чит дәүләтнең вәкаләтле органы яки шәхесне таныклаучы документ бирүгә закон нигезендә вәкаләтле бүтән органнар | Законга туры китереп |
| Балигъ булганнар өчен өстәмә рәвештә тапшырыла: | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Гражданинның, аның гаиләсе әгъзаларының акчалата алынган, аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә, Россия Федерация Хөкүмәтенең 2014 елның "Түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтү өчен, җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында" 18 октябрендәге № 1075 карары нигезендә исәпкә алына һәм соңгы 12 ай эчендә алынган социаль хезмәтләр күрсәткәнгә түләү күләмен исәпләү өчен файдаланыла торган керемнәре булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) <*> | Керемнәр булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | Законга туры китереп |

--------------------------------

<*> № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.2.2 пунктындагы "а" – "е" пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырылмый.

Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты, төп нөсхәләрен күрсәтү факты буенча, гариза бирүчеләрнең шәхси документлары күчермәләрен үзе раслый.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 9 нчы кушымта

**Гражданинны халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Социаль хезмәт алучының шәхесен таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең территориаль органы, хәрби комиссариат бүлеге, Россия Федерациясе Чит илләр белән эшләү министрлыгының Консуллык департаменты, гражданлык хәле актларын теркәү территориаль органы, чит дәүләтнең вәкаләтле органы яки шәхесне таныклаучы документ бирүгә закон нигезендә вәкаләтле бүтән органнар | Законга туры китереп |
| 2. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар | Миграция федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең территориаль органы, опека һәм химаячелек органы | Законга туры китереп |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | <*> | | |
| 3. | Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән индивидуаль программасы <**> | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән |
| 4. | Авыру тарихыннан (амбулатор картадан) өземтә, профилактик прививкалар (балалар өчен), медицина тикшеренүләре нәтиҗәләре турында мәгълүматлар | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |
| 5. | Яшәү урынында йогышлы чирле авырулар белән контактлар булмау турында белешмә | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, социаль тернәкләндерү бүлекләренә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренә өстәмә рәвештә тапшырыла:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Гражданинны ташламалы категориягә кертүне раслаучы билгеләнгән үрнәктәге документ <***> | Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар һәм комиссияләр | Билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелгән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Гражданинның, аның гаиләсе әгъзаларының акчалата алынган, аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә, Россия Федерация Хөкүмәтенең 2014 елның “Түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтү өчен, җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 18 октябрендәге № 1075 карары нигезендә исәпкә алына һәм соңгы 12 ай эчендә алынган социаль хезмәтләр күрсәткәнгә түләү күләмен исәпләү өчен файдаланыла торган керемнәре булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) <****> | Керемнәр булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | Законга туры китереп |

--------------------------------

<*> документлар балигъ булмаганнарны мохтаҗ дип тану өчен тапшырыла;

<**> документ инвалидларны (инвалид балаларны) мохтаҗ дип тану өчен тапшырыла;

<***> № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 3.2.4 пунктындагы “а” – “д” пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырыла.

<****> № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 3.2.4 пунктындагы “а” – “д” пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияле гражданнар өчен тапшырылмый.

Гражданинны инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен, I төркем инвалидларны, 3 яшькә кадәрге яшьтәге балаларны, күренүнең өченче дәрәҗәсендәге теләсә кайсы категориядә тормыш алып барулары чикләнгән инвалид балаларны озатып йөрүчеләр тапшырырга тиешле документлар:

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ | Миграция федераль хезмәтенең территориаль органы, хәрби комиссариат бүлеге, Россия Федерациясе Чит илләр белән эшләү министрлыгының Консуллык департаменты, гражданлык хәле актларын теркәү территориаль органы, чит дәүләтнең вәкаләтле органы яки шәхесне таныклаучы документ бирүгә закон нигезендә вәкаләтле бүтән органнар | Законга туры китереп |
| 2. | Инвалид баланың мәнфәгатьләре буенча эш итү һәм аларны яклауга ышанычнамә | Законлы вәкил тарафыннан рәсмиләштерелә | Ышанычнамәдә күрсәтелгән яисә, ышанычнамәнең гамәлдә булу срогы күрсәтелмәгән булса, 1 ел |
| 3. | Яшәү урынында йогышлы чирле авырулар белән контактлар булмау турында белешмә | Медицина оешмалары | Законга туры китереп |

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 10 нчы кушымта

**Гражданинны сукырлар һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәгендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, гариза бирүче яшәү урынында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) тапшырырга тиешле документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Социаль хезмәт алучының шәхесен таныклаучы документлар | Миграция федераль хезмәтенең территориаль органы, хәрби комиссариат бүлеге, Россия Федерациясе Чит илләр белән эшләү министрлыгының Консуллык департаменты, гражданлык хәле актларын теркәү территориаль органы, чит дәүләтнең вәкаләтле органы яки шәхесне таныклаучы документ бирүгә закон нигезендә вәкаләтле бүтән органнар | Законга туры китереп |
| 2. | Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең Татарстан | Медицина-социаль экспертизаның федераль учреждениеләре | Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән индивидуаль программасы <*> | | күрсәтелгән |

--------------------------------

<*> Инвалидлар (инвалид балалар) өчен тапшырыла.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына 11 нче кушымта

**Гражданинны өендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында торучы һәм гариза бирүче үзе тапшыруга хокуклы документлар исемлеге**

| Т-п № | Тапшырылучы документлар исемлеге | Документны бирүче оешма | Бирелгән көненнән башлап, документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Инвалидны тернәкләндерүнең Министрлыкның территориаль органы мәгълүмат базасында булган, Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән соң төзелгән һәм бирелгән индивидуаль программасы | “Медицина-социаль экспертизаның Татарстан Республикасындагы баш бюросы” федераль казна учреждениесенең структур бүлекчәләре | Инвалидны тернәкләндерүнең Медицина-социаль экспертизаның Татарстан Республикасындагы баш бюросы тарафыннан бирелгән индивидуаль программасында билгеләнгән һәм белешмәдә күрсәтелгән көнгә кадәр |
| 2. | Гражданинның даими яшәү урынында аның белән бергә теркәлгән затлар турында мәгълүматлар | Торакны эксплуатацияләү органнары яки җирле үзидарә органнары | Законга туры китереп |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кергән документ | | |
| 3. | Гражданинның даими яшәү урынында аның белән бергә яшәүче затларны аның гаиләсе әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләрен раслаучы документлар күчермәләре | Россиянең Миграция федераль хезмәтенең территориаль органнары. һәм аларның структур бүлекчәләре; гражданлык хәле актларын теркәү территориаль органнары | Законга туры китереп |
| 4. | Билгеләнгән үрнәктәге, социаль хезмәтләрне түләүсез күрсәтүгә хокукны раслаучы документ | Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар | Билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелгән |
